**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 9 июнь № 386

г. Казань

«Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турында

Татарстан Республикасы оешмаларында эшләүче яшьләрнең иҗади потенциалын ачыклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлар җәмгыяте, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм эшмәкәрләре ассоциациясе (Төбәк эш бирүчеләр берләшмәсе), Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясенең Яшьләр советы, «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары яшьләре берлеге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы, «Артиас» иҗади хезмәткәрләр берләшмәсе» Казан шәһәр җәмәгать оешмасы, «Созвездие-Йолдызлык» Татарстан Республикасы төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы белән берлектә «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

«Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивале турында нигезләмәне;

«Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең массакүләм мәгълүмат чараларында фестивальне әзерләү һәм үткәрү барышын яктыртуны гамәлгә ашырырга.

4. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

«Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлар җәмгыятенә «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестиваленең зона концертларын телевизион трансляцияләүне, финал гала-концертын төшерүне һәм трансляцияләүне тәэмин итүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашуны;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлар җәмгыятенә «Наше время – Безнең заман» Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре иҗатының еллык ачык республика телевизион фестивален үткәрү урыннарында җәмәгать тәртибен һәм гражданнар иминлеген тәэмин итүне.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 июль, 1185-б номерлы, 2014 ел, 22 март, 534-б номерлы, 2015 ел, 16 май, 1010-б номерлы боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков